Коръән укыганда яки зикерләр әйткәндә тел хәрәкәтләнергә тиешме?

هل يشترط تحريك اللسان عند
قراءة القرآن أو الأذكار ؟

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM

سؤال: هل يشترط تحريك اللسان عند قراءة القرآن أو الإتيان بالأذكار ؟

Сорау: Коръән укыганда яки зикерләр әйткәндә тел хәрәкәтләнергә тиешме?

الجواب : ذِكْرُ الله تعالى من أشرف أعمال المسلم ولا يقتصر الذكر على اللسان بل يكون الذِكْرُ بالقلب واللسان والجوارح.

Җавап: Аллаһны искә алу (ягъни зикерләр әйтү) – мөселманның иң бөек (күркәм) гамәлләренең берсе һәм ул тел белән әйтүдә генә чикләнми, ә киресенчә йөрәк, тел һәм тән әгъзалары белән була.

وصفة الذكر بالقلب التفكر في آيات الله ومحبته وتعظيمه والإنابة إليه والخوف منه والتوكل عليه ، وما إلى ذلك من أعمال القلوب.

Аллаһны йөрәк белән искә алу – ул Аллаһ барлыкка китергән, кояш, һава кебек бөек мәхлуклар турында уйлану. Шулай ук Аллаһны ярату, олылау, тәүбә итү, Аннан курку, Аңа тәвәккәл кылу, һәм башка йөрәк гамәлләре.

وأما ذكر الله باللسان فهو النطق بكل قول يُقرِب إلى الله تعالى وأعلاه قول :
لا إله إلا الله

Тел белән зикер итү – ул барлык Аллаһка якынайта торган сүзләрне әйтү. Һәм бу сүзләрнең иң олысы – Лә иләһә илләЛлаһ кәлимәсе.

وأما ذكر الله بالجوارح فبكل فعل يُقرب إلى الله تعالى كالقيام في الصلاة والركوع والسجود والجهاد والزكاة.

Тән әгъзалары белән зикер итү – ул Аллаһка якынайта торган хәрәкәтләр ясау, мәсәлән: намаз вакытында кыямда тору, рөкүг һәм сәҗдә ясау, җиһат кылу, зәкәт бирү.

فكل ذلك ذكر لله تعالى.

Һәм болар барысы да Аллаһны искә алуга керә.

والأذكار تقال باللسان كقراءة القرآن والتسبيح والتحميد والتهليل وأذكار الصباح والمساء والنوم ودخول الخلاء وغيرها لابد فيها من تحريك اللسان ولا يُعدُّ الإنسان قد قالها إلا اذا حرك بها لسانه

Һәм тел белән әйтелә торган зикерләр ул: Коръән уку, тәсбих, тәхмид, тәһлил, иртәнге һәм кичке зикерләр, йокларга ятканда, бәдрәфкә кергәндә һәм башка вакытларда әйтелә торган зикерләр, боларны барысын да әйткәндә тел катнашырга ягъни хәрәкәтләнергә тиеш. Зикер әйткәндә теле хәрәкәтләнгән кеше генә зикер әйткән дип исәпләнә.

وقد سُئل الإمام مالك عن الذي يقرأ في الصلاة لا يُسمع أحدا ولا نفسه ولا يحرك به لسانه ، فقال : ليست هذه قراءة وإنما القراءة ما حُرِكَ له اللسان.

Имам Мәликтән намазында берәү дә ишетелмәслек итеп, хәтта үз-үзен ишетмәс килеш һәм шул ук вакытта телен хәрәкәтләндермәгән кеше турында сорадылар. Һәм ул: "Бу уку түгел, чынлыкта уку – ул телнең хәрәкәтләнүе",-дип җавап бирде.

وسئل الشيخ ابن عثيمين رحمه الله هل يجب تحريك اللسان بالقرآن في الصلاة أو يكفي بالقلب فأجاب :
القراءة لابد أن تكون باللسان ؛
فإذا قرأ الإنسان بقلبه في الصلاة فإن ذلك لا يجزئه.
وكذلك أيضا سائر الأذكار لاتُجزئ بالقلب
بل لابد أن يحرك الإنسان بها لسانه وشفتيه ؛ لأنها أقوال ولا تتحقق إلا بتحريك اللسان والشفتين.

Шулай ук Шәйх ибн Гүсәйминнән (Аллаһ аңа рәхимлек күрсәтсен) сорадылар: "Намазда Коръән укыган вакытта телне хәрәкәтләндерергә кирәкме, я инде йөрәк белән булса да җитәме? Шәйх Гүсәймин бу сорауга болай дип җавап бирде: "Коръән укуда тел хәрәкәтләнергә тиеш. Телне хәрәкәтләндермәгән килеш бары тик йөрәк белән укылган намазга әҗер-савап язылмый.
Шулай ук бары тик йөрәк белән генә әйтелгән зикерләр дә саваплы булмый. Киресенчә кеше аларны әйткәндә телен һәм иреннәрен хәрәкәтләндерергә тиеш, чөнки сүзләр тел һәм иреннәрне хәрәкәтләндергәндә генә гамәлгә аша".